**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Чалпинского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального района**

ул. Центральная, д.35, с. Чалпы, 423324
Тел. (8-5592) 35-5-46,
факс (8-5592) 35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Чалпы авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

Узэк урамы, 35, Чалпы авылы, 423324
Тел. (8-5592) 35-5--46, факс (8-5592)35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «03 » июнь 2019 ел № 61

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Советы 17.04.2018 ел № 7 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру өчен килешү төзү хокукына ачык аукцион документларының типлаштырылган формасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Советының 17.04.2018 ел «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру», 30.03.2013 ел № 2 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» карарлары нигезендә карар чыгарам:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Советы 17.04.2018 ел 7 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру өчен килешү төзү хокукына ачык аукцион документларының типлаштырылган формасына, 18 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешлшр кертергә:

«в) мөрәҗәгать итүче затның — юридик зат исеменнән гамәлләрне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен раслый торган документ (физик затны вазыйфага билгеләү яки сайлау турында карар күчермәсе, аның нигезендә мондый физик зат мөрәҗәгать итүче исеменнән ышанычнамәсез (алга таба — җитәкче) эш итәргә хокуклы. Әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән башка зат эшли икән, аукционда катнашу гаризасында шулай ук мөрәҗәгать итүче исеменнән, Федераль закон нигезендә җәмгыятьнең мөһердән файдалану бурычы каралса, һәм мөрәҗәгать итүченең җитәкчесе (юридик затлар өчен) яисә әлеге җитәкче тарафыннан имзаланган зат яисә мондый ышаныч кәгазенең нотариаль расланган күчермәсен кулланырга тиеш. Күрсәтелгән ышанычнамә гариза бирүченең вәкаләтле җитәкчесе тарафыннан имзаланган очракта, аукционда катнашу гаризасында шулай ук мондый затның вәкаләтләрен раслаучы документ булырга тиеш;".

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Башлык: А.М.Мөхәмәтшин